РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИСАКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСЭК
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

16.09.2025 — №40

Белешмә (өземтә)бирү буенча муниципаль
хезмәт күрсәтү муниципаль хезмәтен күрсәтүнең
административ регламентына үзгәрешләр кертү
турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге

## КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге Башкарма комитетының «Белешмә (өземтә)бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү муниципаль хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 04 апрелдендәге 10 номерлы карары белән расланган Белешмә (өземтә)бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү муниципаль хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктының 4 пунктчасында «мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк» сүзләренә алмаштырырга»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга) http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Исәк авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе — З.Р.Мөхәммәтҗанова